МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.02.2026 №51-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 19 февралендәге 115-осн номерлы боерыгы белән расланган Әгерҗе урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына үзгәрешләр кертү турында

Закондагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Әгерҗе урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентын раслау турында» 2019 елның 19 февралендәге 115-осн номерлы боерыгы (10.04.2020 ел, №292-осн, 01.12.2020 ел, №802-осн, 13.01.2022 ел, №3-осн, 11.12.2023 ел, №571-осн боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Әгерҗе урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А.Барсукова) боерык имзаланган көннән эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары И.Н.Зариповка йөкләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2026 елның 4 февралендәге 51-осн номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 19 февралендәге 115-осн номерлы боерыгы белән расланган Әгерҗе урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1. Керешендә:

«РФ Урман кодексында каралган хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы норматив хокукый актлар (01.01.2023 ел торышы буенча)» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«РФ Урман кодексында каралган хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы норматив хокукый актлар (01.01.2026 ел торышы буенча)

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| **РФ Хөкүмәте актлары** | | |
| 100 статья | Урманнарга һәм алардагы табигать объектларына китерелгән зыянны каплау | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урманнарга һәм аларда булган табигать объектларына китерелгән зыянны каплау үзенчәлекләрен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1730 номерлы карары |
| 96 статья | Федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) турында» 2021 елның 30 июнендәге 1098 номерлы карары |
| 50 статьяның 3 өлеше | Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле агач материалының иң зур күләмен билгеләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле максималь үзагач күләмен билгеләү турында» 2007 елның 22 июнендәге 395 номерлы карары |
| 73 статьяның 4 өлеше | Федераль милектәге урман ресурслары берәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеген арендалау өчен урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары билгеләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль милектәге урман кишәрлеген арендалау буенча урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары турында» 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары |
| 44 статья | Урманнардан сусаклагычлар һәм башка ясалма су | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су объектын файдалануга бирү турында карар |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, диңгез һәм елга портлары территорияләрен булдыру һәм киңәйтү, гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдалану | әзерләү һәм кабул итү турында» 2022 елның 19 гыйнварындагы 18 номерлы карары |
| 45 статья | Урманнардан линия объектларын төзү, аларны үзгәртеп кору, аларны эшләтү өчен файдалану | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе элемтә чыбыкларын һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 1995 елның 9 июнендәге 578 номерлы карары |
| 76 статьяның 3 өлеше | Урман утыртмаларын сату-алу килешүе буенча түләү Федераль милектә, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары милегендә һәм муниципаль милектә торучы җирләрдә әзерләнә торган агач материалы бирәмлеге өчен түләү ставкаларын билгеләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль милектәге урман кишәрлеген арендалау буенча урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары турында» 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары |
| $23^1$ статьяның 3 өлеше, $60^3$ статья | Урманнарда санитар иминлек. Урман утыртмаларын кисүне гамәлгә ашыру тәртибе | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда санитария куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 декабрендәге 2047 номерлы карары |
| $23^1$ статьяның 3 өлеше, 53 статья | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы. | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 7 октябрендәге 1614 номерлы карары,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарны янгына каршы кору чаралары турында» 2025 елның 22 апрелендәге 526 номерлы карары,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман янгыннары аркасында урманнарда барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен федераль башкарма хакимият органнары көчләрен һәм чараларын җәлеп итү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 1464 номерлы карары,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман янгыннары аркасында килеп чыккан урманнардагы гадәттән тыш хәлләр турында» 2011 елның 17 маендагы 376 номерлы карары,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | янгыннарын сүндерү планын һәм аның формаларын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 17 маендагы 377 номерлы карары,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда һәм урман янгыннарында янгын куркынычы турындагы мәгълүматларның дәреслеген контрольдә тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 18 августындагы 687 номерлы карары |
| 22 статьяның 3 өлеше | Урманнарны үзләштерү өлкәсендә инвестиция эшчәнлеге.<br>Урманнарны үзләштерү өлкәсендә өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген төзү һәм раслау | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман комплексын үстерү максатларында өстенлекле инвестиция проектлары турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2018 елның 23 февралендәге 190 номерлы карары |
| 114 статьяның 6 өлеше | Урман-парк зоналарында урнашкан урманнарның функциональ зоналарын билгеләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән урманнар булган җирләрнең чикләрен үзгәртү һәм урман паркs зоналарында урнашкан урманнарда функциональ зоналарны билгеләү ґагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 21 декабрендәге 1755 номерлы карары |
| 13 статья | Урман инфраструктурасы | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Саклагыч урманнар, эксплуатация урманнары һәм резерв урманнары өчен урман инфраструктурасы объектлары исемлеген раслау турында» 2012 елның 17 июлендәге 1283-р номерлы боерыгы |
| 21 статья | Урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, эксплуатациягә кертү һәм эксплуатациядән чыгару, сүтү, бетерү һәм консервацияләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Саклагыч урманнар, эксплуатация урманнары һәм резерв урманнары өчен урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар исемлеге турында» 2022 елның 30 апрелендәге 1084-р номерлы күрсәтмәсе |
| $21^1$ статья | Урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган капиталь булмаган төзелмәләрне, корылмаларны төзү, эксплуатацияләү һәм сүтү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Саклагыч урманнар, эксплуатация урманнары, резерв урманнары өчен урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар төзү һәм эксплуатацияләү» 2022 елның 23 апрелендәге 999-р номерлы боерыгы |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 45 статья | Урманнардан линия объектларын төзү, аларны үзгәртеп кору, аларны эшләтү өчен файдалану | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәрләре хуҗалыгы объектларының саклык зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартларын билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары |
| $73^1$ статьяның 6 өлеше | Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге урман кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Агач материалы әзерләү өчен дәүләт милегендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсен төзү хокукына конкурста катнашучыларның конкурс тәкъдимнәрен бәяләү кагыйдәләрен һәм тәкъдим ителгән шартларны бәяләү һәм агач материалы әзерләү өчен дәүләт милегендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсен төзү хокукына конкурста җиңүчене билгеләүгә нигез булган критерийларны раслау турында» 2019 елның 7 мартындагы 241 номерлы карары |
| $93^1$ статья | Дәүләт урман реестрын алып бару тәртибе | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт урман реестрын алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 25 августындагы 1378 номерлы карары;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Вәкаләтле дәүләт хакимияте органының яисә аңа буйсынучы дәүләт бюджет учреждениесенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан файдаланып алына торган дәүләт урман реестрындагы белешмәләр, документлар һәм материаллар исемлеген раслау турында» 2022 елның 7 сентябрендәге 2565-р номерлы боерыгы |
| **Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы (алга таба – Россия Табигать министрлыгы) норматив актлары** | | |
| 62 статьяның 7 өлеше | Урманнарны торгызу. Урманнарны торгызу кагыйдәләре | «Урманнарны торгызу кагыйдәләрен, урманнарны торгызу проектының формасын, составын, аны килештерү тәртибен, аны килештерүдән баш тарту нигезләрен, шулай ук урманнарны торгызу проектының электрон рәвештәге форматына карата таләпләр раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 1024 номерлы боерык |
| $73^1$ статьяның 7 өлеше | Урман кишәрлеген файдалануга бирү турында бер төр килешү | «Урман кишәрлекләрен түләүле нигездә файдалануга тапшыру турында бер төрдәге шартнамәләрне раслау турында» 2020 елның 30 июлендәге 542 номерлы боерык |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 77 статьяның 7 өлеше | Урман утыртмаларын сату-алу турында бер төрле шартнамә | «Урман утыртмаларын сату-алу турында бер төрдәге шартнамәне раслау турында» 2020 елның 27 июлендәге 488 номерлы боерык |
| $60^{15}$ статья | Сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган агачларны, куаклыкларны, лианаларны, башка урман үсемлекләрен саклау үзенчәлекләре | «Россия Федерациясе Кызыл китабына яисә Россия Федерациясе субъектлары кызыл китапларына кертелгән, сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган агачларны, куакларны, лианаларны, бүтән урман үсемлекләрен саклау үзенчәлекләрен раслау турында» 2025 елның 27 мартындагы 142 номерлы боерыгы |
| $23^{1}$ статьяның 3 өлеше, 64 статьяның 3 өлеше | Урманнарны карап тору.<br>Урманнарны карап тору кагыйдәләре.<br>Урман утыртмаларын кисүне гамәлгә ашыру тәртибе | «Урманнарны карау кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 30 июлендәге 534 номерлы боерык |
| 112 статьяның 5 өлеше | Махсус саклanучы табигать территорияләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яңадан үрчетү үзенчәлекләре | «Махсус саклана торган табигать территорияләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, торгызу үзенчәлекләрен раслау турында» 2021 елның 12 августындагы 558 номерлы боерык |
| $53^{1}$ статья | Урман янгыннарын кисәтү | «Урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чараларының төрләрен, урманнан файдаланучы затларның әлеге чаралар белән тәэмин ителеш нормативларын, урманнардан файдаланганда урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чараларының булу нормаларын раслау турында» 2025 елның 9 апрелендәге 183 номерлы боерык |
| $53^{2}$ статья | Урманнарда янгын куркынычын һәм урман янгыннарын күзәтеп тору | «Урманнарда янгын куркынычына һәм урман янгыннарына мониторинг ясау тәртибен раслау турында» 2025 елның 12 маендагы 256 номерлы боерык |
| 15 статьяның 3 өлеше | Урман үсә торган зоналар һәм урманлы районнар | «Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урман районнары исемлеген раслау турында» 2014 елның 18 августындагы 367 номерлы боерык |
| 87 статьяның 7 өлеше | Урман хуҗалыгы регламентларының составы, аларны эшләү тәртибе, аларның гамәлдә булу чорлары һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе | «Урман хуҗалыгы регламентларының составын, аларны эшләү тәртибен, аларның гамәлдә булу вакытын һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында» 2017 елның 27 февралендәге 72 номерлы боерык |
| $60^{5}$ статья | Урман авырулары буенча дәүләт мониторингы | «Урман патологиясе буенча дәүләт мониторингын гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 5 апрелендәге 156 номерлы боерык |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| $60^{7}$ статья | Зарарлы организмнар таралуын кисәтү | «Зарарлы организмнарның таралуын кисәтү чараларын гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 912 номерлы боерык |
| $60^{6}$ статьяның 4 өлеше | Урман авыруларына бәйле тикшеренүләр. Урман авыруларына бәйле тикшеренүләрне уздыру тәртибе | «Урман авыруларына бәйле тикшеренүләрне уздыру тәртибен һәм урман авыруларына бәйле тикшеренү актының рәвешен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 910 номерлы боерык |
| $23^{2}$ статьяның 10 өлеше, 29 статьяның 11 өлеше, $23^{1}$ статьяның 3 өлеше | Диләнке эшләре.<br>Агач материалы әзерләү.<br>Агач материалы әзерләү кагыйдәләре. Урман утыртмаларын кисүне гамәлгә ашыру тәртибе | «Агач материалы әзерләү кагыйдәләрен һәм Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясында күрсәтелгән урманчылыкларда агач материалы әзерләү үзенчәлекләрен раслау турында» 2020 елның 1 декабрендәге 993 номерлы боерык,<br>«Диләнке эшләре төрләрен, аларны башкару тәртибен һәм эзлеклелеген, диләнке эшләренең технологик картасы формасын, урман бүлемтеген актыкка тикшерү акты формасын һәм урман бүлемтеген актыкка карап чыгу тәртибен раслау турында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 23 номерлы боерык,<br>«Урман бүлемтегенең таксация тасвирламасына кертелә торган мәгълүматлар составын, урман бүлемтегенең таксация тасвирламасын төзү тәртибен, аның электрон форматындагы форматына карата таләпләрне, урман бүлемтегенең таксация тасвирламасының урман бүлемтегенең хакыйкый торышы турындагы мәгълүматка туры килмәвен билгеләү тәртибен, урман бүлемтегенең таксация тасвирламасы формасын раслау турында» 2022 елның 14 октябрендәге 687 номерлы боерык |
| $60^{4}$ статья | Урманнарны саклау буенча районнарга бүлү | «Урман саклык районнарына бүлү тәртибен раслау турында» 2017 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы боерык |
| $70^{1}$ статьяның 13 өлеше | Урман кишәрлекләрен проектлау | «Урман кишәрлегенең проект документациясе составына һәм эчтәлегенә, аны әзерләү тәртибенә карата таләпләрне раслау турында» 2017 елның 3 февралендәге 54 номерлы боерык |
| $60^{13}$ статья | Урманнарны радиоактив пычранудан саклау үзенчәлекләре | «Урманнарның радиоактив пычрану зоналарында профилактика һәм тернәкләндерү чараларын гамәлгә ашыру үзенчәлекләрен раслау турында» 2017 елның 8 июнендәге 283 номерлы боерык |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| $66^5$, $66^6$, $66^7$, $66^8$ статьялар | Урман орлыкчылыгы | «Урман орлыкчылыгы объектларын (урман-орлык плантацияләрен, даими урман-орлык кишәрлекләрен, башка урман утыртмаларын, урман үсемлекләре орлыкларын, үсентеләрне, урман агач токымнары чәчкеннәрен җитештерү (үстерү, җыю), шулай ук урман үсемлекләренең генофондын саклау һәм нәселдәнлек үзлекләрен өйрәнү максатларында файдаланыла торган урман орлыкчылыгы объектларын) төзү, аерып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 25 апрелендәге 231 номерлы боерык,<br>«Урман үсемлекләре орлыкларын, төп урман агач токымнары үсентеләрен, чәчүлекләрен җитештерү (үстерү, җыю), аларның категорияләрен билгеләү, саклау, транспортировкалау, сату һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» 2025 елның 15 маендагы 269 номерлы боерык |
| 46 статьяның 4 өлеше | Урман эшкәртүче фраструктура объектларын төзү һәм алардан файдалану | «Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын төзү һәм алардан файдалану өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 31 гыйнварындагы 54 номерлы боерык |
| 38 статья | Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану | «Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен һәм Урман кишәрлеген бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләп яки билгеләмичә генә урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 2 июлендәге 408 номерлы боерык |
| 49 статьяның 4 өлеше | Урманнардан файдалану турында хисап.<br>Урманнардан файдалану турында хисап тапшыру тәртибе | «Урманнардан файдалану турындагы хисапка кертелә торган мәгълүмат исемлеген, бу мәгълүматны теркәү тәртибен, урманнардан файдалану турындагы хисапны тапшыру рәвешен һәм тәртибен, шулай ук урманнардан файдалану турында электрон формадагы хисап форматына таләпләр раслау турында» 2025 елның 19 мартындагы 115 номерлы боерык |
| 66 статьяның 4 өлеше | Урманнарны яңадан үрчетү һәм урман үстерү турында хисап. Урманнарны торгызу һәм урман үрчетү турында хисап тапшыру тәртибе | «Урманнарны торгызу һәм урман үрчетү турында хисапка кертелә торган мәгълүмат исемлеген, бу мәгълүматны теркәү тәртибен, урманнарны торгызу һәм урман үрчетү турында хисапны тапшыру рәвешен һәм тәртибен, шулай ук урманнарны торгызу һәм |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | урман үрчетү турында электрон формадагы хисап форматына таләпләр раслау турында» 2025 елның 18 мартындагы 112 номерлы боерык |
| 89 статья | Урманнарны үзләштерү проектына дәүләт экспертизасы һәм муниципаль экспертиза. | «Урманнарны үзләштерү проектына дәүләт экспертизасы һәм муниципаль экспертиза тәртибен раслау турында» 2020 елның 30 июлендәге 513 номерлы боерык |
| 26 статьяның 3 өлеше | Урман декларациясе.<br>Урман декларациясен тутыру һәм тапшыру тәртибе | «Урман декларациясенең формасын, аны тутыру һәм тапшыру тәртибен, электрон рәвештә урман декларациясе форматына таләпләр раслау турында» 2021 елның 29 апрелендәге 303 номерлы боерык |
| 60 статьяның 3 өлеше, $60^{11}$ статьяның 3 өлеше | Урманнарны янгыннардан саклау турында хисап.<br>Урманнарны янгыннардан саклау турында хисап тапшыру тәртибе.<br>Урманнарны яклау турында хисап.<br>Урманнарны саклау турында хисапны тапшыру тәртибе. | «Урманнарны янгыннардан саклау турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнарны янгыннардан саклау турында хисап формасын һәм аны тапшыру тәртибен, шулай ук урманнарны янгыннардан саклау турында электрон рәвештә хисап тапшыру форматына карата таләпләр, урманнарны саклау турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнарны саклау турында хисап формасын һәм аны тапшыру тәртибен, шулай ук урманнарны саклау турында электрон рәвештә хисап форматына карата таләпләр раслау турында» 2025 елның 18 мартындагы 111 номерлы боерык |
| $60^{8}$ статьяның 5 өлеше | Зыянлы организмнар чыганакларын бетерү | «Зыянлы организмнарның чыганакларын юк итү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 913 номерлы боерык |
| $53^{4}$ статья | Урман янгыннарын сүндерү | «Урман янгыннарын сүндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 1 апрелендәге 244 номерлы боерык |
| $98^{2}$ статья | Урманнарны саклау | «Урманнарны саклауны гамәлгә ашыру тәртибен һәм нормативларын раслау турында» 2021 елның 15 декабрендәге 955 номерлы боерык |
| $64^{1}$ статьяның 2 өлеше | Урманнарны торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман урнашкан җирләргә кертү | «Урманнарны торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман урнашкан җирләргә кертү тәртибен һәм тиешле акт рәвешен раслау турында» 2019 елның 11 мартындагы 150 номерлы боерык |
| 86 статьяның 5 өлеше | Россия Федерациясе субъекты урман планы.<br>Россия Федерациясе | «Россия Федерациясе субъекты урман планының бертип формасын һәм составын, аны әзерләү һәм үзгәрешләр кертү тәртибен |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | субъектының урман планы составы һәм аны әзерләү тәртибе | раслау турында» 2017 елның 20 декабрендәге 692 номерлы боерык |
| 32 статья | Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу | «Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу турында» 2020 елның 28 июлендәге 496 номерлы боерык |
| 67 статья, 68 статья | Урман корылышы турында гомуми нигезләмәләр<br>Урман корылышының эчтәлеге | «Урман корылышы буенча файдалану күрсәтмәсен раслау турында» 2022 елның 5 августындагы 510 номерлы боерык |
| 63 статьяның 3 өлеше | Урман үстерү. Урман үстерү кагыйдәләре | «Урман үстерү кагыйдәләрен, урман үстерү проектының формасын, составын, аны килештерү тәртибен, аны килештерүдән баш тарту нигезләрен, шулай ук урман үстерү проектының электрон рәвештәге форматына карата таләпләр раслау турында» 2021 елның 20 декабрендәге 978 номерлы боерык |
| 88 статьяның 2 өлеше | Урманнарны үзләштерү проекты. | «Урманнарны үзләштерү проектының составын, аны эшләү һәм аңа үзгәрешләр кертү тәртибен, электрон документ рәвешендә урманнарны үзләштерү проекты форматына карата таләпләр раслау турында» 2021 елның 16 ноябрендәге 864 номерлы боерык |
| 39[1] статья | Урман питомникларын булдыру һәм аларны эксплуатацияләү | «Урман питомникларын төзү һәм аларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 12 октябрендәге 737 номерлы боерык |
| 45 статья | Урманнардан линия объектларын төзү, аларны үзгәртеп кору, аларны эшләтү өчен файдалану | «Урманнардан линия объектларын төзү, аларны үзгәртеп кору, аларны эшләтү өчен файдалану кагыйдәләрен һәм, сервитут, гавами сервитут билгеләп яки билгеләмичә, урман кишәрлеген бирмичә урманнардан линия объектларын төзү, аларны үзгәртеп кору, аларны эшләтү өчен файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 10 июлендәге 434 номерлы боерык |
| 43 статья | Җир астын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләре | «Урманнардан җир астын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару өчен файдалану кагыйдәләрен һәм, җир кишәрлеге бирмичә, сервитут билгеләп яки билгеләмичә, урманнардан җир астын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару өчен файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 7 июлендәге 417 номерлы боерык |
| 31 статья | Чәер әзерләү | «Чәер әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 911 номерлы |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | боерык |
| $38^1$ статья | Урманнардан балыкчылыкны гамәлгә ашыру өчен файдалану | «Урманнардан балыкчылыкны гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 13 октябрендәге 742 номерлы боерык |
| 39 статья | Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре, дару үләннәре үстерү | «Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 497 номерлы боерык |
| 34 статья | Азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыю | «Азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үләннәрен әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 494 номерлы боерык |
| 40 статья | Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану | «Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 27 июлендәге 487 номерлы боерык |
| 41 статья | Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану | «Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 908 номерлы боерык |
| 29 статьяның 7 өлеше, 81 статьяның 3 пункты | Агач материалы әзерләү. Агачын әзерләү рөхсәт ителми торган агачларның һәм куаклыкларның төрләре (токымнары) исемлеге | «Агач материалын әзерләү рөхсәт ителми торган агачларның һәм куаклыкларның төрләре (токымнары) исемлеген раслау турында» 2011 елның 5 декабрендәге 513 номерлы боерык |
| 53 статьяның 4 өлеше, $53^1$ статья | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы. Урман янгыннарын кисәтү | «Урманнарны янгынга каршы төзекләндерү нормативларын билгеләү турында» 2025 елның 9 апрелендәге 184 номерлы боерык |
| **Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы норматив актлары (алга таба – Рослесхоз)** | | |
| 29 статьяның 6 өлеше | Файдалану өчен исәпләнгән диләнкене исәпләп чыгару тәртибе, кисентеләрнең яше | «Файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләмен исәпләп чыгару тәртибен раслау турында» 2011 елның 27 маендагы 191 номерлы боерык,<br>«Кисентеләрнең яшен билгеләү турында» 2015 елның 9 апрелендәге 105 номерлы боерык |
| 53 статьяның 4 өлеше, $53^1$ статья | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы. Урман янгыннарын кисәтү | «Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясен һәм, һава шартларына карап, урманнарда табигый янгын куркынычы классификациясен раслау турында» 2011 елның 5 июлендәге 287 номерлы боерык |
| $66^5$ статья | Урман орлыкчылыгы | «Урман орлыкларын үстерү районнарын билгеләү турында» 2022 елның 19 декабрендәге 1032 номерлы боерык |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| **Россия Федерациясе субъекты норматив актлары** | | |
| 82, 83 статьялар | Урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре.<br>Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тапшыру | «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы,<br>Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман планын раслау турында» 2018 елның 24 декабрендәге ПУ-880 номерлы Указы,<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 30 июлендәге 531 номерлы карары,<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының региональ яки муниципальара әһәмияттәге гомуми автомобиль юллары исемлеген раслау турында» 2025 елның 1 мартындагы 121 номерлы карары |
| 82 статьяның 7 өлеше | Татарстан Республикасында гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләү ставкаларын билгеләү | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләү ставкаларын билгеләү турында» 2020 елның 7 октябрендәге 107-2/нпс-2020 номерлы карары |

»;

2. 1.2 бүлекнең 5 нче таблицасына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| Тикшеренү эшчәнлеген гамәлгә ашыру | Әгерҗе | 1-49, 51-80, 82-90, 92-116, 118-146 кварталлар | 9263 |
| | Девятернә | 1-47, 49-64 кварталлар | 6400 |
| | Красный бор | 1-7, 9-38, 43-51, 56-60, 64-101, 103-185 кварталлар | 16007 |
| | Шаршады | 1-113, 115-125, 128-133, 136-156 кварталлар | 13676 |
| | Җәмгысе | | 44346 |

».